СОВЕТ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

____________________ с. Сарманово №_______________

**05.11.2024 ел № 236**

**«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» нигезләмә» 2018 елның 13 августындагы 130 номерлы Сарман муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, рәис урынбасарларына, аудиторларына хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы карары , Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Сарман муниципаль районы Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең акчалата тәэмин итү турында» 2018 елның 13 августындагы 130 номерлы нигезләмәне (Сарман муниципаль районы Советының 2018 елның 10 декабрендәге 153 номерлы, 22.06.2020 № 242, 07.09.2020 № 253, 14.09.2022, № 100 номерлы, 12.2022, № 116, 20.05.2024 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне кертеп) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаның 2 пунктында карарга «13 323» санын «13 990» санына алмаштырырга.

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Җирле үзидарә органнары һәм муниципаль орган җитәкчеләренә үзләре чыгарган хокукый актларны әлеге карарга туры китерүне йөкләргә.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

5. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә әлеге карарны игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сарман муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципальн район

Советы рәисе Ф.М. Хөснуллин